# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
# К А Р А Р

14.03.2016 № 20

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 13 марттагы җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

«2017 елда Урта Курса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 800 сум күләмендә (түләү күләме 400 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең исеме | Планлаштырылган чаралар | Сату өчен акча күләме /сум. |
|---|---|---|---|
| 1 | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - торак пунктларга янгын гидрантлары сатып алу;:<br>Түбән Курса авылы<br>Алан авылы<br>Корайван авылы<br>Сарай-Чокырча авылы | <br><br>6 000 руб.<br>6 000 руб.<br>6 000 руб.<br>6 000 руб. |
| 2 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларны ремонтлау (вак таш, торбалар сатып алу)<br>Югары Курса авылында<br>Урта Курса авылы<br>Түбән Курса авылы<br>Алан авылы<br>Сарай-Чокырча авылы | <br><br>100 000<br>60 000<br>110 000<br>60 000<br>46 000 |
| 3 | Күмү урыннарын карап тоту | - зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту;:<br>Урта Курса авылы<br>Корайван авылы | <br><br>25 000<br>15 000 |
| 4 | Төзекләндерү эшләрен | Урта Курса авылында чишмә | 3 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | оештыру | ремонтлау,<br>- Алан, Корайван, Урта Курса, Югары Курса авылларында яшел үсентеләрне санитар кисү;<br>- Урта Курса авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда урам яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру; | <br>10 000<br><br><br>10 000 |
| 5 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - кое ремонты.:<br>Алан авылында<br>Югары Курса авылында | <br>17 000<br>30 000 |
| | ИТОГО | | 510 000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга”.

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 752 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны - 617, бу 82,05% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 585 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 94,81% тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 32 кеше тавыш бирде, бу 5,19% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. «2017 елда Урта Курса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 800 сум күләмендә (түләү күләме 400 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең исеме | Планлаштырылган чаралар | Сату өчен акча күләме /сум. |
|---|---|---|---|
| 1 | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - торак пунктларга янгын гидрантлары сатып алу;:<br>Түбән Курса авылы<br>Алан авылы<br>Корайван авылы<br>Сарай-Чокырча авылы | <br><br>6 000 руб.<br>6 000 руб.<br>6 000 руб.<br>6 000 руб. |
| 2 | Җирлекнең җирле | - юлларны ремонтлау (вак таш, | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | торбалар сатып алу)<br>Югары Курса авылында<br>Урта Курса авылы<br>Түбән Курса авылы<br>Алан авылы<br>Сарай-Чокырча авылы | <br>100 000<br>60 000<br>110 000<br>60 000<br>46 000 |
| 3 | Күмү урыннарын карап тоту | - зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту;:<br>Урта Курса авылы<br>Корайван авылы | <br><br>25 000<br>15 000 |
| 4 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | Урта Курса авылында чишмә ремонтлау,<br>- Алан, Корайван, Урта Курса, Югары Курса авылларында яшел үсентеләрне санитар кисү;<br>- Урта Курса авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда урам яктырткычларын алыштыру һәм урнаштыру; | 3 000<br><br>10 000<br><br><br>10 000 |
| 5 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | - кое ремонты.:<br>Алан авылында<br>Югары Курса авылында | <br>17 000<br>30 000 |
| | ИТОГО | | 510 000 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга".

соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева